ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАТАРСКО-ЕЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР-ЯЛТАНЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422975, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
с.Татарский Елтан, ул.Хамзина, 50

422975, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Татар Ялтаны авылы
авылы,
Хамзин ур., 150

тел. 884342 3-47-33, e-mail: Telt.Ctp@tatar.ru

Постановление | Карар

2020 елның 16 июле | №9

Сайлау алды басма агитация материалларын
урнаштыру өчен махсус урыннар турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” гы 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 54 статьясындагы 7 пункты, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты, дүртенче чакырылыш Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы депутатлары сайлауларын һәм 2020 елның 13 сентябрендәге 28 номерлы Түбән Кама бермандатлы сайлау округы буенча җиденче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты өстәмә сайлауларын үткәргәндә Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлеге территориясендә сайлау алды басма агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирергә һәм җиһазландырырга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, белдерүләр стендларында һәм такталарында, шулай ук «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/, шулай ук "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татар Ялтаны
авыл җирлеге башлыгы _____________ Р.Р.Гәрифуллин

Татар Ялтаны авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 16 июлендәге
9 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Президенты, дүртенче чакырылыш Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы депутатлары сайлауларын һәм 2020 елның 13 сентябрендәге 28 номерлы Түбән Кама бермандатлы сайлау округы буенча җиденче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты өстәмә сайлауларын үткәргәндә Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлеге территориясендә сайлау алды басма агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар исемлеге

| Сайлау участогы номеры | Сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урын адресы | Урнаштыру урыны исеме |
|---|---|---|
| 2775 | Татар Ялтаны авылы, Кооперативная ур., 6 нчы йорт<br>Кооперативная ур., 9 нчы йорт<br>Изгар авылы, Школьная ур., 13/1 нчы йорт | Кибет бинасы<br>Авыл клубы бинасы<br>2 нче администрация бинасы |